**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 27 гыйнвар № 42

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Акланган затларны күмүгә бәйле чыгымнарны каплау тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2007 ел, 5 июль, 270 нче карары белән расланган Акланган затларны күмүгә бәйле чыгымнарны каплау тәртибе турында нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Акланган затларны күмүгә бәйле чыгымнарны каплау тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2007 ел, 5 июль, 270 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 21 июнь, 496 нчы, 2013 ел, 12 март, 157 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган  Акланган затларны күмүгә бәйле чыгымнарны каплау тәртибе турында нигезләмәне яңа редакциядә бәян итеп (теркәлгән), үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\42.docx

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 5 июль, 270 нче карары белән расланды (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 27 гыйнвар, 42 нче карары редакциясендә)

**Акланган затларны күмүгә бәйле чыгымнарны каплау тәртибе турында нигезләмә**

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Акланган затларны күмүгә бәйле чыгымнарны каплау тәртибе турында нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) акланган затларны күмүгә бәйле чыгымнарны каплау тәртибен регламентлаштыра.

1.2. Акланган затларны күмүгә бәйле чыгымнарны каплау турында карарлар «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» казна учреждениесе бүлекләре (алга таба – РМЯҮ бүлекләре) тарафыннан кабул ителә.

2. Акланган затларны күмүгә бәйле чыгымнарны каплау шартлары һәм тәртибе

2.1. Акланган затларны күмүгә бәйле чыгымнарны каплау акланган затларны күмүне гамәлгә ашыру йөкләмәсен үзләренә алган гражданнар һәм оешмалар (алга таба – гариза бирүче) тарафыннан, күмү буенча түбәндәге хезмәтләргә түләү өчен кирәкле күләмдә башкарыла:

күмү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү;

күмү өчен кирәкле табут һәм предметларны бирү һәм китереп бирү;

үлгән кешенең мәетен (үлегән) зиратка (крематорийга) алып килү;

күмү (көле белән савытны биреп, кремацияләү).

Өстәмә хезмәт төрләре гариза бирүче исәбеннән түләнә.

2.2. Акланган затларны күмүгә бәйле чыгымнарны каплау өчен гариза бирүчеләр, аларның законлы вәкилләре яки билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән ышанычнамә нигезендә алар тарафыннан вәкаләтләр бирелгән затлар акланган затның Татарстан Республикасында соңгы яшәү урыны буенча РМЯҮ бүлекләренә түбәндәгеләрне тапшыра:

акланган затны күмүгә бәйле чыгымнарны каплау турында гариза;

башкарылган чыгымнар булуын раслый торган түләү документлары;

аклану турында документ күчермәсе.

РМЯҮ бүлегендә үлгән кешенең аклану фактын раслый торган белешмәләр булганда, гариза бирүче аклану турында документ күчермәсен тапшырудан азат ителә.

2.3. Гариза бирүчеләр, аларның законлы вәкилләре яки Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышанычнамә нигезендә алар тарафыннан вәкаләтләр бирелгән затлар гариза белән мөрәҗәгать иткәндә шәхесне таныклаучы документны, банкта яки бүтән кредит учреждениесендә ачылган исәп-хисап счеты реквизитларын күрсәтәләр.

Гариза һәм акланган затны күмүгә бәйле чыгымнарны каплау өчен кирәкле документлар (белешмәләр) электрон документлар рәвешендә җибәрелә ала. Электрон документлар рәвешендә җибәрелгән гаризалар һәм документлар Россия Федерациясе законнары нигезендә электрон имза белән имзалана һәм электрон мәгълүмат йөртү әсбаплары һәм (яки), «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрен дә кертеп, гомуми кулланылыштагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләрен файдаланып тапшырыла.

Гариза һәм акланган затны күмүгә бәйле чыгымнарны каплау өчен кирәкле документлар (белешмәләр) электрон документлар рәвешендә җибәрелгәндә гариза бирүче акланган затны күмүгә бәйле чыгымнарны каплау өчен кирәкле максатларда һәм күләмдә үзенең персональ мәгълүматларын файдалануга ризалыгын белдерә.

2.4. РМЯҮ бүлеге ведомствоара электрон багланышлар тәртибендә әлеге Нигезләмәнең 2.2 пунктчасында күрсәтелгән гаризаны һәм документларны тапшырган көннән соң ике эш көне эчендә граждан хәле актларын теркәү органнарыннан акланган затның үлемен дәүләт теркәвенә алу турында мәгълүматларны үз эченә алган документларны соратып ала.

Акланган затларны күмүгә бәйле чыгымнарны каплау максатларында гариза бирүчеләр, аларның законлы вәкилләре яки Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышанычнамә нигезендә алар тарафыннан вәкаләтләр бирелгән затлар үз башлангычлары белән Үзәк бүлегенә әлеге пунктта күрсәтелгән белешмәләрне үз эченә алган документлар тапшырырга хокуклы.

2.5. РМЯҮ бүлеге барлык кирәкле документлары белән гариза бирелгән көннән соң биш эш көне эчендә акланган затны күмүгә бәйле чыгымнарны каплау (каплаудан баш тарту) турында карар кабул итә.

2.6. Гариза бирүчегә акланган затны күмүгә бәйле чыгымнарны каплау тиешле документларны РМЯҮ бүлегенә тапшырган датадан алып өч ай эчендә башкарыла, әгәр сорап мөрәҗәгать итү акланган зат үлгән көненнән соң алты айдан да соңга калмыйча башкарылса.

2.7. Акланган затларны күмүгә бәйле чыгымнарны каплаудан баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

тапшырылган документлардагы мәгълүматларның дөрес булмавы;

әлеге Нигезләмәнең 2.2 пунктчасында күрсәтелгән документлар акланган зат үлгән көненнән соң алты ай узгач тапшырылу.

## 3. Акланган затларны күмүгә бәйле чыгымнарның капланырга тиешлесен билгеләү

3.1. Акланган затларны күмүгә бәйле чыгымнар РМЯҮ тарафыннан Татарстан Республикасы бюджеты акчасы хисабына, әлеге Нигезләмәнең 2.1 пунктчасында

күрсәтелгән күмү буенча хезмәтләр чикләрендә, күмүгә түләнә торган социаль пособиене тотып калып, каплананалар.

3.2. Әлеге Нигезләмәнең 2.1 пунктчасында күрсәтелгән күмү буенча хезмәтләрнең бәясе Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге, Россия Федерациясе Социаль иминиятләү фондының Татарстан Республикасы буенча төбәк бүлеге, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы белән килештереп, җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләнә.

3.3. Гариза бирүчегә акланган затны күмүгә бәйле чыгымнарны каплау җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләнгән һәм акланган зат үлгән моментта гамәлдә булган күмү буенча хезмәтләргә минималь бәяләр һәм тарифлардан чыгып башкарыла.

## 4. Акланган затларны күмүгә бәйле чыгымнарны каплауны финанслау

4.1. Акланган затларны күмүгә бәйле чыгымнарны каплау буенча чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итү күрсәтелгән максатларга тиешле финанс елына Татарстан Республикасы бюджеты турында законда каралган бюджет ассигнованияләре хисабына һәм алар кысаларында гамәлгә ашырыла.

4.2. Акланган затларны күмүгә бәйле чыгымнарны каплау мәсьәләләре буенча бәхәсләр гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә хәл ителә.

F:\KARAR\2016\42.docx